КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 февраль г.Казань № 107

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт казна учреждениеләрен кушу рәвешендә үзгәртеп кору турында» 2017 ел, 1 март, 124 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 6 март, 139 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1322 нче һәм 2023 ел, 1 ноябрь, 1389 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

өченче абзацта «271,25» саннарын «251,25» саннарына алмаштырырга;

җиденче абзацта татар текстында «, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү» сүзләрен төшереп калдырырга, «гражданның» сүзеннән соң «өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«озак вакыт карау системасы эшчәнлеген тәэмин итү буенча төбәк һәм территориаль координация үзәге функцияләрен гамәлгә ашыру.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат санын билгеләү турында» 2017 ел, 22 июль, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 ноябрь, 1181 нче һәм 2024 ел, 4 июль, 509 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) хезмәткәрләренең иң чик штат санын 2026 елның 1 маеннан «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы

бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган Үзәкнең хезмәт өчен түләү фондын 2027 елга кадәр өстәмә кертелгән 20 берәмлек тоту акчасын исәпкә алып саклау шарты белән 359 берәмлек күләмендә билгеләргә.».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

60 көн эчендә «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Ресурс үзәге) һәм «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) уставларына тиешле үзгәрешләрне кертергә;

Ресурс үзәге һәм Үзәк тарафыннан әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле кирәкле оештыру-штат чараларын үткәрүне һәм эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә хезмәт законнарында каралган гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Бу карар (әлеге карарның 2026 елның 1 маеннан үз көченә керә торган 1 һәм 2 пунктларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин